5.8.1. — Общая педагогика, история педагогики и образования

**Ссылка для цитирования:**
Хакимова Г.Ш. Мәктәп укучыларын патриотик тәрбияләүдә музей педагогикасы // Современное образование: актуальные вопросы и инновации. 2024. № 2 (21).
URL: http://irortsmi.ru/wp-content/uploads/2024/07/2024_2_khakimova.pdf

УДК 37.01

**Гульнара Шариповна Хакимова**
учитель татарского языка и литературы высшей квалификационной категории, Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Амикеевская основная общеобразовательная школа», Муслюмовский район, Республика Татарстан

## Мәктәп укучыларын патриотик тәрбияләүдә музей педагогикасы

***Аннотация.*** Заманча мәктәп тәрбия эшен үстерү максатларында аңа тәкъдим ителгән барлык мөмкинлекләрне, шул исәптән музей педагогикасын да куллана. Музей педагогикасы ярдәмендә балаларда игелек, Ватанга мәхәббәт, патриотизм, туган як һәм Ватан өчен горурлык һ.б. кебек мөһим әхлакый сыйфатлар формалаша, ягъни хәзерге яшьләрнең социаль-мәдәни коды формалаша. Музей педагогикасы элементларын кулланганда, мәктәп музее базасында түгәрәккә йөрүче укучылар туганнары белән бергә дәресләргә йөри ала, ә аннары белемнәрен, мәсәлән, үз шәҗәрәләрен төзү, туган як үзенчәлекләрен, аның көнкүрешен, табигатен тасвирлау өчен куллана ала. Укучылар башкарган эшләрнең күбесе конкурста катнашкан һәм призлар белән билгеләнгән.

***Төп сүзләр***: музей, мәдәни мирас, матди һәм рухи мәдәният һәйкәлләре, белем бирү-тәрбия эше

**Gul’nara Sh. Khakimova**
Teacher of Tatar Language and Literature, Amikey Basic General School, Muslumov district, Republic of Tatarstan, Russia

## Museum Pedagogy in Patriotic Education of Schoolchildren

***Abstract.*** The modern school uses all the possibilities offered to it, including museum pedagogy, in order to develop educational work. It is well known that with the help of museum pedagogy children form the most important moral qualities, such as kindness, love for the motherland, patriotism, pride for their native land and fatherland etc. etc. e. formed the socio-cultural code of modern youth. When using the elements of museum pedagogy, students attending the club on the basis of the school museum, have the opportunity to attend classes with relatives, and then use knowledge, for example, to compile their genealogy, describe the features of their native land, his lifestyle, nature, etc. Most of the works that the students performed, participated in the competition and were awarded with prizes.

***Keywords:*** Museum, cultural heritage, monuments of material and spiritual culture, educational work

*Музей — бер чакта да үлми торган тере тарих ул*
*Аяз Гыйләҗев*

### Кереш

Рухи-әхлакый тәрбия бирү педагогик-психологик яктан оештырылган процесс. Аның төп максаты — укучыларны яшәп килгән милли традицияләрне сакларга өйрәтү, халкына, туган иленә карата патриотик хисләр тәрбияләү; җәмгыятьнең мәдәни, рухи, әхлакый кыйммәтләрен үзләштерергә һәм аларны дөрес кабул итәргә ярдәм итү, бай рухи тормышка әзерләү. Милли үзаңы югары булган балага толерантлык, ирекле хезмәттәшлеккә һәм тынычлыкка омтылу, туган илен яра-

© Хакимова Г.Ш., 2024

ту хас. Бу сыйфатларга ия булган укучыда иң югары омтылышлар, идеаллар, бай рухи дөнья формалаштыру авыр түгел. Бүгенге мәктәпнең иң төп бурычы да шулар. Философ Сенека фикеренчә: «Гыйлемлелектә алга китеп тә, әхлак ягыннан артта калган кеше алга китүдән дә бигрәк артта калып яши». Чыннан да, бала белемле булып та, кешелексез булып үсә икән, бу безнең эшебезнең дөрес оештырылмавын күрсәтә. Балага рухи-әхлакый тәрбия бирүнең төп бурычы аңа иркле шәхес булып үсәргә, иң кирәкле рухи кыйммәтләрне сайлап ала һәм аларны тормышта максатчан куллана белергә өйрәтү. Бу проблема һәрвакыт актуаль булып калачак, чөнки әхлак, игелек өстенлек алганда гына киләчәк ышанычлы, өметле булачак.

Бүгенге көндә тагын бер әһәмиятле мәсьәләгә игътибар итми һич ярамый. Бу — толерантлык мәсьәләсе. Замана укучысы, һәр кешенең нинди милләттән булуына карамастан, аны кабул итәргә, башкаларның традицияләрен, карашларын, хокукларын хөрмәт итәргә һәм аларга зыян, комачаулык китермичә яшәргә тиеш. Бу төшенчәләр — гомумкешелек кыйммәтләре дип аталалар. Бу кыйммәтләрне тәрбияләүдә бердәнбер юл — ул да булса рухи-әхлак тәрбиясе бирү. Бу бурычны тормышка ашыруда мәктәп музейлары, алар алып барган эшчәнлекнең роле зур.

**Төп өлеш**

Ватан — кешеләрнең хөрмәте һәм һәркем хозурында тора торган кадерле бер мактанычыдыр...Шуның өчен малыгызны кызганмагыз,көчләрегезне аямагыз, Ватан хакына болай фидакяр булмаган кеше анда яшәргә лаек түгелдер.

Риза Фәхретдин.

19нчы гасырда яшәгән бөек мәгърифәтче Риза Фәхретдиннең Ватанга мәхәббәт турындагы бу нәсихәте бар кеше өчендә шигарь итеп алырлык.

Туган илнең патриоты булу өчен ниләр эшләргә кирәк? Шагыйрь туган илен үзенең шигырь-җырларында данлый, солдат-офицерлар илне сакларга тиеш.Ә укытучы буларак, минем вазифам, бурычым нидән гыйбарәт? Бүгенге көндә мин үземнән илебезнең киләчәге өчен нинди өлеш кертә алам?

Мин менә шушы сорауларга җавап табарга телим. Минем уйлавымча, беренче чиратта, укытучы үзе патриот булырга тиеш.Чын патриот янында янәшәдәгеләр горурлык хисе генә түгел, ә киләсе көнгә ышаныч та тоялар.

Яшь буынга әхлак, патриотик һәм рухи тәрбия бирүдә нинди үтемле чаралар кулланырга соң?

Минемчә, патриотизм орлыклары гаиләдә үк салынырга тиеш. Кешенең нинди мохиттә тәрбияләнүе тормышта зур роль уйный. Бишек җырларыннан, ана теленнән башлап, яшәү дәвамында үзләштерелүче әхлакый гомумкешелек кыйммәтләре — барысы да патриотизм тәрбияләү өчен мөһим шарт булып тора. Ә укытучының һәр дәресе, бигрәк тә тарих, әдәбият дәресләре патриотик тәрбия бирү мәктәбе булырга тиеш.

Патриотик тәрбия бирүнең беренче адымы — туган якны яратырга өйрәтү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, мин укучыларымда туган табигатькә, милли традицияләргә, милли мәдәниятkә, туган телебезгә мәхәббәт тәрбияләргә омтылам.

Патриотик тәрбия бирүнең икенче адымы — туган як тарихын өйрәнү. Туган як тарихы ул — шунда яшәгән кешеләр тарихы. Кешенең тарихта тамырлары гаиләсенең традицияләрендә, халкының, туган ягының үткәнендә. Мин — туган як тарихын өйрәнү түгәрәге җитәкчесе, укучыларыма бу юнәлештә нәрсә бирә алам?

Туган як тарихын өйрәнү укучыларга үз төбәкләрендә яшәгән кешеләр турында күбрәк белергә, якыннан танышырга мөмкинлек бирә. Аларның тормыш-яшәешләре укучыларда соклану һәм горурлану хисләре уята, өлкән буын кешеләренә карата хөрмәт тәрбияли. Мин үз эшчәнлегемдә укучыларга «Сез шул кешеләргә алмашка килүче буын, тарихны сез язачаксыз, илебез тарихы сез төзегәнчә булачак», — дип аңлатырга тырышам. Без үсеп килүче буынга үзенең әтисе, гаиләсе, буыны эшләрен дәвам итүче икәнен,

аны тормышы, нәселе дәүләтнең һәм, ниһаять, илнең бер кисәге икәнен аңлатырга тиешбез.

Үз тарихын белмәгән халыкның киләчәге юк. Моның өчен һәр бала үз гаиләсенең тарихын белергә, шуның аркылы халык тарихына якынаерга тиеш. Шәҗәрәләр төзү нәсел-ыру традицияләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, әдәп-әхлагын, кәсепләрен белү һәм дәвам иттерү өчен кирәк. Шулай булганда гына яшь кеше милләт җанлы, үз халкының улы булып җитлегә ала.

Шул максаттан чыгып, түгәрәккә йөрүче укучылар үз гаиләләренең тарихын, һөнәр-шөгыльләрен бик кызыксынып өйрәнделәр һәм нәсел шәҗәрәләрен төзеделәр. Аларны «Шәҗәрәләр — гаиләм тарихы» дигән альбомга тупладык. Эшләрне төрле конкурсларга җибәрдек. Укучыларым республика күләмендә призлы урыннарга лаек булдылар. Түгәрәк әгъзалары белән гаилә шәҗәрәләрен генә түгел, ә авылыбыздан чыккан күренекле кешеләрнең нәсел шәҗәрәләрен дә төзибез. Авылдашыбыз шагыйрь, язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, К. Насыйри һәм А. Грибоедов премияләре һәм Тукай премиясе лауреаты, филология фәннәре кандидаты Факил Сафинның шәҗәрәсен төзедек. Авылыбызның күренекле кешеләренә карата патриотизм, әхлак, туган якка мәхәббәт, милли үзаң тәрбияләүдә Сафиннар гаиләсенең роле бик зур.Укучым Җәлилова Алсу бу хезмәт белән Буада үткәрелгән төбәкара «Шәҗәрәләр — нәсел агачы» конкурсында җиңү яулады.

Патриотик тәрбия бирүдә тагын мөһим чараларның берсе — музейлардагы хәзинәне — тарихи экспонатларны, халкыбызның рухи һәм матди культурасын, бүгенгесен һәм узганын чагылдыручы кыйммәтле материалларны куллану. Укучыларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә мәктәп музейлары зур әһәмияткә ия. Музейлар шулай ук туган якның, туган авылның, туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәм итә.

Туган як тарихын өйрәнү түгәрәге әгъзалары белән без интернет челтәрендә авылыбыз тарихына багышланган «Якты йолдыз булып яна Әмәкәй күңелемдә» һәм «Туган як музее» исемле үз сайтларыбызны булдырдык. Авылыбыз сайты берничә тапкыр Халыкара «Белем җәүһәрләре» интернет-проеклар конкурсында призлы урынга лаек булды.

Яңа технологияләрне кулланып, туган телебездә интернет-проект эшләү интернет челтәре аша дөньяның барлык төбәкләренә дә туган ягыбыз турында мәгълүмат җиткерү мөмкинлеге бирә, укучыларда сайт ясау серләренә төшенү, материалны урнаштыра белү күнекмәләре формалаштыра. Интернет-проект эшен башкару вакытында алган белемнәр үткән тарихыбызны аңларга ярдәм итә. Фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнү туган якка кызыксыну уята. Интернет-проект авыл тарихын, традицияләрен, гореф-гадәтләрен, колхоз төзелү, мәктәп-мәдрәсәләр тарихын, авылыбыздан чыккан күренекле кешеләрнең тормыш юлын, укытучы-ветераннар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, әфганчылар турында һ.б. мәгълүматларны үз эченә ала. Актуальлеге — үз халкыңның тарихын, традицияләрен, гореф-гадәтләрен белүче шәхес тәрбияләү — безнең төп бурыч. Интернет-проект төзү интернет челтәре аша аралашу мөмкинлеге тудыра, кызыксынган кешеләрне эшчәнлеккә тарта.

Укучыларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә мәктәп музейлары зур әһәмияткә ия. Музейлар шулай ук туган якның, туган авылның, туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәм итә.

Безнең мәктәптә дә туган якны өйрәнү музее 1994 нче елдан эшли.Аңа нигез салучы-тарих укытучысы Мирзаянова Гөлсинә

Шәехҗановна. Ул 1994–2005 елларда музей белән җитәкчелек итте. Музейны оештыру, материаллар җыюда күп көч куйды. Музейга 1998 елда Татарстан Мәгариф министрлыгы тарафыннан «Мәктәп музее» статусы бирелде. Музейда эшчәнлек күпкырлы юнәлештә алып барыла.Түбәндәге бүлекләр эшли: авыл тарихы, мәктәп тарихы, этнография-тормыш-көнкүреш әйберләре, якташларыбыз Ватан сугышында, нумизматика, әфганчылар.

Мәктәптә музей булдыру өчен 1993 елдан экспонатлар туплый башланды.Бу елларда туган як тарихын өйрәнү түгәрәгенә йөрүче укучылар Мирзаянова Гөлсинә Шәехҗановна җитәкчелегендә авыл халкы арасына чыгып, авыл, мәктәп тарихы турында, авылның күренекле кешеләренә багышланган материаллар, фоторәсемнәр, экспонатлар тупладылар. Хәзерге көндә музейда 1200 экспонат бар, туплау эше дәвам итә.

Музей материаллары, экспонатлар дәресләрдә, класс сәгатьләрендә, театр атналыклары һәм төрле кичәләрдә файдаланыла. Музейга материаллар килү дәвам итә. Авыл халкы да кызыксына, очрашуларга кайткан мәктәпнең элекке укучылары, читтән кайткан кунаклар, очрашуга килгән сугыш ветераннары, өлкәннәр, башка мәктәп укучылары һәм укытучылары музейның даими кунаклары булып торалар. Мәктәптә үткәрелгән район методик берләшмәләрнең семинар-киңәшмәләрендә катнашкан укытучылар да музей белән танышып, үзләренең җылы фикерләрен җиткерәләр.

Патриотик тәрбия бирүне халкыбыз узган сугышчан юл белән таныштыру аша алып бару гаять тә отышлы дип саныйм. Туган илне ихтирам итү, патриотизм хисләрен туган җиреннән аерылып, Ватан өчен утка кергән авылдашлар язмышы, аларның кичерешләре аша тәрбияләүдән дә отышлырак чара бармы соң? Сугыш һәм тыл ветраннары белән очрашулар, ялгыз яшәүче әби-бабайларга ярдәм күрсәтү — һәрберсе дә укучылар күңелендә өлкән буынга хөрмәт тәрбияли. Музейга кергән һәр бала ветераннарга багышланган стенд, альбом, экспонатларны күрә, бигрәк тә кече яшьтәгеләр ныграк кызыксына, күп сораулар яудыралар. Алар моннан илебез азатлыгы өчен көрәшкән кешеләрнең исемнәре алдагы буыннарга җитәчәген аңлап чыга.

Мин — мәктәпнең Туган як музее җитәкчесе, музейда үткәрелгән очрашулар, экскурсия, дәресләр, туган якка кагылышлы җирле материалларны өйрәтү аша балалар күңеленә патриотизм орлыклары салырга тырышам. Мәктәптә үткәрелгән әдәби кичәләр — укучыларга, чын-чынлап, илһам чыганагы. Балаларга алдагы буыннарның бай тормыш тәҗрибәсен өйрәтү, тарихы, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру кебек максатларга ирешү өчен музей материаллары — чиксез бай хәзинә.

Музеебыз «Җиңү» региональ проектында катнашып, лауреат булды. Конкурста катнашучылар «Иң яхшы музей» номинациясендә Бөек Ватан сугышы тарихын чагылдырган музей экспозицияләре, патриотик юнәлештәге фәнни-тикшеренү һәм класстан тыш эшләр, публикацияләр, җирлек белән башка формадагы эшләр тәкъдим иттеләр. Музейга ТР мәгариф һәм фән министрлыгы дипломы һәм истәлекле бүләк тапшырылды.

**Йомгаклау**

Йомгак ясап шуны әйтергә телим: укучыларга патриотик тәрбия бирү кирәк кенә түгел, ә мәҗбүри. Бүгенге заманда бигрәк тә. Чөнки һәр бала, үскән саен, үзенең Ватанына кирәклеген тоярга тиеш. Ватан, Туган ил ул бик тирән мәгънәгә ия төшенчә, ул әниең, ул синең туган йортың, мәктәбең, дусларың, синең яшәгән дөньяң... Һәркем үз халкының лаеклы улы, лаеклы вәкиле булырга тиеш. Халыкның даны аның данлы уллары белән булдырыла.

Минем теләгем: барлык балалар да, шулай ук бөтен гражданнар да үз туган илләрен, Ватаннарын яратсыннар иде. Әгәр дә кешенең туган, яшәгән урынына мәхәббәте юк икән, ул инде кеше түгел, ниндидер бер үзенең тумышын аңламый торган затка әйләнә. Патриотик тәрбия бирүне барың бергә тормышка ашырырга кирәк. Ул укытучы, мәктәп эше генә түгел, ә һәрбер гражданның һәм шул

ук вакытта дәүләт эше дә булырга тиеш. Туган илнең чын гражданины аның үсешенә үз өлешен кертмәсә, бернәрсә дә үзгәрмәячәк.

Туган ил ул — туган йортыбыз.Ә үз йортыбызга без битарафлык, явызлык кебек начар сыйфатларны кертергә тиеш түгел. Әгәр дә укучыларымның һәрберсе туган йортыбызга игелек, мәрхәмәт, кешелеклелек, мәхәббәттән өлеш кертсә, мин үземнең бурычымны үтәлде дип санар идем.

Кулланылган әдәбият

1. Әхмәтгалиев, Ә.Ә. Мөслим төбәге. Тарихи сәхифәләр / Ә.Ә. Әхмәтгалиев. — Яр Чаллы, 2003.
2. Воспитание патриотизма, сохранение и развитие родных языков в условиях регионального этнокультурного пространства: материалы республиканской научно-практической конференции. — Арск, 2021. — Вып. 1. — 773 с.
3. Зарипов, С. Бай тарихлы төбәгем / С. Зарипов // «Авыл утлары» газетасы. — 1995. — 14 октябрь.
4. Кәримов, Т. Әмәкәй авылы тарихы / Т. Кәримов // «Авыл утлары» газетасы. — 1996. — 17 август.
5. Туган якны өйрәнү музее: сайт. — URL: http://nahmuzei.blogspot.com
6. «Якты йолдыз булып яна Әмәкәй күңелемдә» сайты. URL: https://tugan-awlm.blogspot.com/

References

1. Akhmetgaliev A. A. Muslumov region. Historical pages. Naberezhnye Chelny, 2003. (In Tat.)
2. Education of patriotism, preservation and development of native languages in the regional ethnocultural space: materials of the republican scientific and practical conference. Arsk, 2021. Issue 1, 773 p.
3. Zaripov S. Bai tarikhly təbəgem. Avyl utlarY gazetasy. 1995, 14 October. (In Tat.)
4. Karimov T. Amikei village history. Avyl utlarY gazetasy. 1996, 17 August. (In Tat.)
5. Tugan yakny өirənү muzee. URL: http://nahmuzei.blogspot.com
6. Yakty ioldyz bulyp yana Əməkəi kүңelemdə. URL: https://tugan-awlm.blogspot.com